РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ШЕМОРДАНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
422050, Республика Татарстан,
Сабинский район,
с. Шемордан, ул. Лермонтова, 2
тел. (84362) 3-21-44

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ШЭМЭРДЭН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

422050, Татарстан Республикасы,
Саба районы,
Шэмэрдэн авылы Лермонтов урамы,
2 йорт

тел. (84362) 3-21-44

e-mail: Shmd.Sab@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ — КАРАР

12.02.2021 — № 10 - п

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Шәмәрдән авыл җирлеге Башкарма комитетының 23.04.2019 ел, №81-п карары белән расланган агач һәм куаклар кисүгә, төпләүгә яки утыртуга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы, Татарстан Республикасы буенча Федераль салым хезмәте идарәсе, Татарстан Республикасы буенча Федераль казначылык идарәсенең 2020 елга Татарстан Республикасы берләштерелгән бюджетын үтәү йомгаклары һәм 2021 елга республика финанс, казначылык һәм салым органнарының бурычлары буенча берләштерелгән коллегиясенең 04.01.2021 ел №4-ПР беркетмәсен үтәү йезеннән, Саба муниципаль районы Шәмәрдән авыл җирлеге башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Саба муниципаль районы Шәмәрдән авыл җирлеге башкарма комитетының «Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» 23.04.2019 ел, №81-п карары белән расланган агач һәм куак кисүгә, төпләүгә яисә утыртуга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2.6 пункттагы таблицаның икенче баганасына түбәндәге эчтәлекле 2) пункт естәргә:

«Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурычлар булмау турында мәгълүматлар-Россия ФСХ.»;

1.2. 2.8 пунктындагы таблицаның икенче баганасына түбәндәге эчтәлекле 5) пункт естәргә::

5) Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурычлар булу.»;

1.3. 3.4.1 Пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.4.1. Башкарма комитет секретаре электрон формада ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша җавап бирү турында сорау җибәрә:

1) күчемсез милеккә һәм аның белән алыш-бирешләргә хокукларның бердәм дәүләт реестрыннан еземтәләр (күчемсез милек объектына теркәлгән хокуклар турында һәркем өчен мөмкин булган мәгълүматлар).

2) законнарны бозган өчен салымнар, җыемнар, пеняләр һәм штрафлар түләү буенча бурычлар булу (булмау) турында белешмәләр.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза кергән көннән алып бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: җибәрелгән сорау».

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru һәм Саба муниципаль районының рәсми сайтында: http://saby.tatarstan.ru адресы буенча бастырып чыгарырга.

Авыл җирлеге башлыгы А.Н.Гәрәев